| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУСЛЮМОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕТАБЫНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ТҮБӘН ТАБЫН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

***№ 14*** ***с. Верхний Табын*** ***05.07.2024г.***

**«2024-2027 нче елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Башкарма комитетының «20» июнь 2024 елдагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2024-2027 нче елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «20» июнь 2024 елгы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 5.3 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5.3. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар үткәрү һәм уңай иҗтимагый климат булдыру максатыннан массакүләм мәгълүмат чараларында үткәрелә торган чараларны яктырту | Җирлекнең Башкарма комитеты | Җирлек бюджеты (10 мең сум) | 2024 е.– 3 б.<br>2025 е.- 4 б.<br>2026 е.- 4 б.<br>2027 е. – 5 б. |

1.2. 1 нче кушымтаның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы - агымдагы финанслау 10 000,00 сум, шул исәптән:<br>- авыл җирлеге бюджеты - 10 000,00 сум.<br>Программаны район авыл җирлеге бюджетыннан финанслау күләме ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы нигезендә төгәллләштерелечәк.<br>Финанслау күләме кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар уздыруга һәм уңайлы шартлар тудыру максатында массакүләм мәгълүмат чараларында уздырыла торган чараларны яктыртуга юнәлтелгән.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

***Татарстан Республикасы***
***Мөслим муниципаль районы***
***Түбән Табын авыл җирлеге***
***башкарма комитеты җитәкчесе*** ***Р.Ш. Кыяметдинов***